ЧӘРШӘМБЕ
6 ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 4 (6726)
Аерым номеры 15 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ПРОИЗВОДСТВОНЫ РАЦИОНАЛЛАШТЫРУ—ЭШЛӘП ЧЫГАРУНЫ КҮТӘРҮДӘ ЗУР ЭТӘРГЕЧ

Иптәш Сталин Октябрь Социалистик Революциясенең 25 еллыгына багышлаган докладында безнең промышленностебызның эшенә яхшы бәя бирде. Немец-фашист басып алучыларына каршы совет халкының бөек Ватан сугышы көннәрендә үзләренең бөтен көчләрен, бөтен энергияләрен биреп эшләүче эшчеләр, инженер-техник работниклар һәм хезмәткәрләр бу бәяне алуга хаклылар. Алар гитлерчыларның канлы өерен җимерүдә Кызыл Армиягә ярдәмнәрен тагын да көчәйтергә омтылып, фронтка сугыш коралларын эшләп чыгаруны көннән-көн арттыралар, тыл кирәк-яракларын торган саен күбрәк җитештерә баралар.

Стахановчылар, инженерлар, техниклар, конструкторлар, уйлап табучылар һәм рационализаторлар—болар барысы да безнең промышленностьның алдынгы кешеләре. Сугыш вакытында бу кешеләр үзләренең барлык иҗади сәләтлелекләрен илебезнең оборона куәтен көчәйтүгә юнәлдерделәр. Хәзер кайсы гына предприятиегә барсаң да, анда уйлап табучылык-рационализаторлык хәрәкәтенең киң колач җәйгәнен күрәсең.

Производствоны рационаллаштыру—эшләп чыгаруны күтәрүдә зур этәргеч. Моның шулай икәнлеген бик күп фактлардан күрергә була. Баш инженеры иптәш Кадышев булган заводта, группа начальнигы иптәш Макарычева бер объектның конструкциясен гадиләштерергә тәкъдим керткән. Аның тәкъдимен тормышка ашыру аркасында хезмәт җитештерүчәнлеге 40 процентка күтәрелгән, бу, 26 эшчене ул объекттан азат итәргә мөмкинлек биргән.

Яки менә икенче факт. Баш инженеры иптәш Касаткин булган заводта технологик процессны яңадан карап чыгу, эшкәртүнең рационаллаштырылган методларын үзләштерү аркасында 250.000 эш сәгатенә экономия ясалган. Бу да бит хезмәт җитештерүчәнлегенең шактый күтәрелүе, эшләп чыгаруның бик нык артуы турында сөйли.

Дәүләт оборона Комитетының күчмә Кызыл Байрагын алуга лаеклы булган Н-че заводта (баш инженеры иптәш Зафьянцев) яңа технология кертү нәтиҗәсендә кайбер детальләр буенча эшләп чыгару 25 процентган 40 процентка кадәр арткан. Завод сан ягыннан күп, сыйфат ягыннан яхшы продукция бирә. Моның өстенә продукциянең үзенә төшү бәясе 7,5 процентка кимегелгән.

Слесарь Казаковның (баш инженер иптәш Корнеев булган завод) станокта шестерняларны болтлар белән беркетү чарасын уйлап табуы һәм шуның нәтиҗәсендә бу станокның эшләп чыгарышын берничә тапкырга арттыруы кебек фактларны йөзләрчә санарга мөмкин. Уйлап табучылар һәм рационализаторлар белән эш яхшы куелган урыннарда бу хәрәкәт киң җәелеп, үзенең гүзәл нәтиҗәләрен торган саен күбрәк бирә бара.

Хәзерге вакытта производствода рационаллаштыру һәм уйлап табучылык эшенең әһәмияте безгә бик аңлаешлы. Шулай булгач бу мәсьәләгә игътибарны көчәйтергә кирәк. Үзенең иҗат фикере белән производствога ярдәм итәргә теләгән һәрбер кеше конкрет игътибар һәм кайгыртучанлык белән чолганып алынырга тиеш. Уйлап табу һәм рационаллаштыру тәкъдимнәренең озак вакытлар буена каралмый ятулары яки каралып яхшы дип табылып та үз вакытында тормышка ашырылмавы кебек фактлар белән һич тә килешеп торырга мөмкин түгел.

Алдынгы кешеләрнең—рационализаторларның һәм уйлап табучыларның иҗат фикерләрен эшләп чыгаруны арттыруга, продукциянең сыйфатын яхшыртуга юнәлдерү белән бергә, ягулыкка һәм электр энергиясенә, материалларга, эш көченә һәм эш вакытына нык экономия режимы кертү мәсьәләсенә дә юнәлдерергә кирәк. Аларга җитәкчелекне һәръяклап көчәйтергә, аларның конкрет эшләре белән кызыксынып, кирәк вакытта конкрет ярдәм оештырырга, барлык шартларны тудырырга! Хуҗалык работникларының, партия, комсомол, профсоюз оешмаларының бу юнәлештәге бурычлары әнә шулар.

Соңгы сәгатьтә

I

4 нче январьда безнең гаскәрләр, кискен атакадан соң, НАЛЬЧИК шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

5 нче январьда безнең гаскәрләр ПРОХЛАДНЫЙ шәһәрен һәм тимер юл узелын, МАЙСКОЕ шәһәрен һәм КОТЛЯРЕВСКАЯ тимер юл узелын алдылар.

Каты сугыш нәтиҗәсендә безнең гаскәрләр МОРОЗОВСКИЙ шәһәрен һәм тимер юл станциясен, шулай ук ЦЫМЛЯНСКАЯ район үзәген алдылар.

Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

II

ТӨНЬЯК КАВКАЗДА безнең гаскәрләр 1942 нче елның 24 нче декабреннан 1943 нче елның 4 нче январена кадәр немец оккупантларга каршы сугышларда түбәндәге трофейларны кулга төшерделәр: 150 танк; 109 орудие; 268 пулемет; 5.000 ләп винтовка; танкка һәм пехотага каршы куела торган 59.000 мина; 500.000 нән артык патрон, 253 автомашина; сугыш припаслары һәм азык тутырылган 15 склад.

Шул ук вакыт эчендә дошманның 18 самолеты; 170 танкысы; 42 орудиесе; 222 пулемет; йөкләр һәм сугыш снаряжениесе төялгән 390 автомашинасы юк ителде.

1942 нче елның 24 нче декабреннан 1943 нче елның 4 нче январена кадәр булган вакыт эчендә дошманның үтерелгән солдат һәм офицерлары гына да 11.000 нән артык.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

ГРУЗИЯ ССР, БОРЧАЛИ РАЙОНЫ, „СОЦИАЛИЗМ" КОЛХОЗЫ

КОЛХОЗ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ КОРБАНОВ МОХТАР КАРА ОГЛЫНА

Кызыл Армиянең һава көчләре турында кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен минем сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен кабул итегез, иптәш Корбанов Мохтар Кара оглы. **И. СТАЛИН.**

ГРУЗИЯ ССР, ЛЕНИНГОРСК РАЙОНЫ, «УКРАИНА-УБАНИ» АВЫЛЫ, ВОРОШИЛОВ ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗ

Колхозчы ГЕОРГИЙ АЛЕКСЕЕВИЧ БАШОРУЛИГА

Кызыл Армиянең һава көчләре турында кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен минем сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен кабул итегез, Георгий Алексеевич.

И. СТАЛИН.

МОСКВА ӨЛКӘСЕ; КОЛОМНА РАЙОНЫ; ДИМИТРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗ

Колхоз председателе Степан Григорьевич Алишкинга

Кызыл Армиянең бронетанк көчләре турында кайгыртучанлык күрсәткән өчен Сезгә рәхмәт, Степан Григорьевич.

Сәламемне кабул итегез.

И. СТАЛИН.

Москва, Кремль, ИОСИФ ВИССАРИОНОВИЧ СТАЛИНГА

Рус православия чиркәве исеменнән Сезне чын күңелдән котлыйм. Яңа елда гыйбадәт кылып, Сезгә сәламәтлек һәм Сезгә ышанып тапшырылган туган ил файдасына Сезнең барлык башлаган эшләрегездә уңыш телим. Димитрий Донской исемендәге танклар колоннасы төзү өчен ярдәм итәргә руханиларны, дингә ышанучыларны махсус хатыбыз белән чакырам. Бу эшне башлап җибәрү өчен патриархия 100.000 сум, Москвадагы Елохово кафедраль соборы 300.000 сум, собор настоятеле Николай Федорович Колчицкий 100.000 сум кертәләр. Дәүләт банкысында махсус счет ачуны үтенәм. Сезнең җитәкчелегегездәге бөтен халыкның батыр эше фашизмның канлы көчләрен җиңү белән тәгәлләнсен.

Патриарх урынын биләүче
Москва митрополиты СЕРГИЙ

УЛЬЯНОВСК.

Патриарх урынын биләүче Москва митрополиты СЕРГИЙГА

Кызыл Армиянең бронетанк көчләре турында кайгыртучанлык күрсәткән өчен рус православия руханиларына һәм дингә ышанучыларга минем сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшыруыгызны үтенәм.

Дәүләт банкысында махсус счет ачу турында күрсәтмә бирелде.

И. СТАЛИН.

ЧКАЛОВ ӨЛКӘСЕНЕҢ ЗИЯНЧУРИН РАЙОНЫ, «КРАСНЫЙ ОВЦЕВОД» КОЛХОЗЫ

Колхозчы Владимир Александрович Людиженскийга

Кызыл Армиянең бронетанк көчләре турында кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен Сезгә рәхмәт белдерәм, Владимир Александрович.

Сәламемне кабул итегез.

И. СТАЛИН.

АКТҮБӘ ӨЛКӘСЕНЕҢ МОРТУК РАЙОНЫ, «СВЕТ» КОЛХОЗЫ

Колхозчы Дария Васильевна МАРЗЕНКОГА

Кызыл Армиянең бронетанк көчләре турында кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен рәхмәт Сезгә, Дария Васильевна.

Сәламемне кабул итегез.

И. СТАЛИН.

САРАТОВ ӨЛКӘСЕНЕҢ РОМАНОВСКИЙ РАЙОНЫ, РЕВВОЕНСОВЕТ ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗ

Колхозчы Андрей Васильевич БОЛОТНИКОВКА

Кызыл Армиянең бронетанк көчләре турында Сезнең кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен Сезгә, Андрей Васильевич, рәхмәт белдерәм.

Сәламемне кабул итегез.

И. СТАЛИН.

ТАҖИКСТАН ССР НЫҢ КУЛЯБ РАЙОНЫ, КАГАНОВИЧ ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗ

Колхозчы АТА ОДИНАЕВКА

Кызыл Армиянең бронетанк көчләре турында Сезнең кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен Сезгә рәхмәт белдерәм, иптәш Одинаев.

Сәламемне кабул итегез.

И. СТАЛИН.

ВОЛОГДА ӨЛКӘСЕНЕҢ КУБЕНО-ОЗЕРСКИЙ РАЙОНЫ, «НОВЫЙ ПУТЬ» КОЛХОЗЫ

Колхоз председателе иптәш Анна Федоровна ПЕРЯЕВАГА

Кызыл Армиянең бронетанк көчләре турында Сезнең кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен Сезгә, Анна Федоровна, рәхмәт белдерәм.

Сәламемне кабул итегез.

И. СТАЛИН.

ОБОРОНА ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫНДА

Оборона Халык Комиссариаты Кызыл Армиянең личный составы өчен хәзерге вакытта яшәп килә торган аерымлык билгеләре урынына яңа аерымлык билгеләре—погоннар кертү турында СССР Верховный Советы Президиумы алдында үтенеч кузгатты.



ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (Ленинград фронты. Рәсемдә: командиры өлкән сержант П. Долгушев булган орудие расчеты дошман ДЗОТ ына туры наводкадан ата.
ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

5 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

5 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр Донның урта агымы районында, Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак, Үзәк фронтта һәм Төньяк Кавказда элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинград районында безнең гаскәрләр дошманга каршы ут сугышы һәм разведка алып бардылар. Заводлар районында безнең подразделениеләр төнлә белән гитлерчылар урнашкан урынга барып керделәр һәм берничә бинаны алдылар. Сталинградтан төньяк - көнбатыштарак совет артиллеристлары немецларның 7 ДЗОТ ын һәм блиндажын җимерделәр, бер сугыш припаслары складын шартлаттылар һәм бер рота дошман пехотасын таркаттылар.

* * *

Сталинградтан көньяк - көнбатыштарак һәм көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта безнең артиллеристлар немецларның төшү площадкасында тора торган 11 самолетын юк иттеләр, бер артиллерия һәм бер миномет батареясының утын бастырдылар. Икенче бер участокта немецлар контратака ясап карадылар, ләкин, пулемет уты белән һәм мылтык залпы белән каршы алынып, тәртипсез рәвештә элекке позицияләренә чигенделәр. Сугыш кырында дошманның күп үлә гәүдәләре калды.

* * *

Донның урта агымы районында безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Бер участокта дошманның әле яңа гына фронтка килгән көчләренә каршы сугыш башланып китте. Башта немецлар безнең подразделениеләрне бераз кысрыклый алдылар. Шуннан соң сугышка совет танкистлары керде. Безнең танклар, дошманга фланггтан удар ясап, гитлерчыларның хәрби сафларын бутадылар, аларны авыр югалтуларга дучар иттеләр һәм чигенергә мәҗбүр иттеләр. Дошманның 49 танкысы зарарланды һәм яндырылды, берничә йөз немец солдаты һәм офицеры юк ителде. Икенче бер участокта безнең сугышчылар, чигенүче дошманны куып барып, халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар.

* * *

Үзәк фронтта, Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак, Н-че часть сугышчылары, дошманның мина кырларын һәм тимер чыбык киртәләрен үтеп, дошман оборонасының көчле рәвештә ныгытылган узелына бәреп керделәр. Бик каты бәрелештән соң, дошман бу узелдан бәреп чыгарылды. 9 пулемет, 4 миномет, бер радиостанция һәм бер сугыш припаслары склады кулга төшерелде.

Ржевтан көнбатыштагы районда безнең частьлар дошманның вак группаларының атакаларын кире кайтардылар. Совет разведчиклары төнлә белән немецлар тылына барып чыгып, 30 гитлерчыны кырып ташладылар һәм берничә ДЗОТ ны шартлаттылар.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр алга баруларында дәвам иттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер зур авыл районында аеруча каты сугыш булды. Немецлар контратакага шактый күп пехота һәм танклар җибәрделәр. Безнең пехотачыларны озата баручы артиллеристлар ут ачып, дошманның 8 танкысын сафтан чыгардылар. Совет сугышчылары, штык һәм приклад белән хәрәкәт итеп, гитлерчыларны тар-мар иттеләр һәм авылны алдылар. Сугыш кырында дошманның 330 үлә гәүдәсе калды. Беренче алынган сводкага караганда, Моздок шәһәрен алган чакта безнең бер частебыз гына да немецларның ике батальонын тар-мар иткән, 15 танк, 8 орудие, бер поход автомастерское, сугыш припаслары тутырылган 2 зур склад, күп кенә мотоцикллар һәм велосипедлар кулга төшерелгән.

* * *

Ленинград фронтында безнең снайперлар 3 көн эчендә 479 гитлерчыны юк иттеләр. Артиллерия уты белән дошманның 45 ДЗОТ ы һәм блиндажы җимертелде, 2 сугыш припаслары склады шартлатылды.

* * *

Орел партизаннарының бер группасы немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Зенит орудиеләре төялгән 7 платформа, танклар төялгән 10 платформа һәм солдатлар утырган 2 вагон җимерелгән. Орел өлкәсендә хәрәкәт итүче икенче бер отрядның партизаннары бер хәрби эшелонны һәлак итүне оештырганнар. 200 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары үтерелгән.

* * *

Котельниково районында немецларның 6 нчы танк дивизиясеннән унтер-офицер Эмиль К. Кызыл Армия ягына чыкты. Ул болай диде: «Соңгы вакытларга кадәр безнең дивизия Франциядә иде. Сталинград районында руслар һөҗүмгә күчкәч күп кенә немец частьлары өстәмә рәвештә Франциядән Көнчыгышка күчерелделәр. Мәсәлән, 1942 нче елның ноябрендә 337 нче пехота дивизиясе Россиягә җибәрелде. 1940 нчы елның мартыннан бирле бу дивизия Франциядә тора иде. Шуның артыннан озак та үтми, ашыгыч рәвештә безнең танк дивизиясе дә шунда җибәрелде. Хәзер инде, «СС» дивизияләрен исәпләмәгәндә, Франциядә, гадәттәгечә барлы-юклы солдатлардан гына җыйналган частьлар гына калды. Мәсәлән, резерв батальоннарында тылда гарнизонлык хезмәте яки тыл частьларында стройдан тыш хезмәт алып барырга гына яраклы дип табылган солдатлар бик күп».

* * *

Яңа ел төнендә Бельгия патриотлары Брюссельдә берничә немец оккупантны үтергәннәр. Немец офицерлары яңа елны каршыларга җыелган кафега берничә граната ташланган. Гитлерчылар арасында күп кенә үлүчеләр һәм яралаучылар бар.

Колхоз җитәкчеләрен тәрбияләү

Колхоз авылының күп кенә батыр һәм эшчән уллары Ватан сугышына киттеләр. Фронтка киткән иптәшләр арасында партоешма секретарьлары, колхоз председательләре, тракторчылар, комбайнчылар, машинистлар, агрономнар һәм башкалар бар.

Ләкин, бу иптәшләр китү белән эш туктальп калмады. Киң катлау колхоз массасы арасыннан яңа кадрлар үсеп чыктылар һәм алар җитәкчелек постларына бастылар. Бу кадрларны тәрбияләү, аларга көндәлек эштә практик ярдәм күрсәтү буенча урындагы партоешмалар алдына гаять җаваплы бурычлар килеп басты.

Менә бу бурычларны үтәү буенча ВКП(б) ның Әтнә райкомы, политбүлек белән берлектә, шактый эшләр эшләде. Авыл советы һәм колхоз председательләре, ферма мөдирләре, бригадирлар һәм башкалар белән берничә тапкыр курс-семинарлар үткәрелде. Аларга практик ярдәм күрсәтү өчен ВКП(б) райкомының инструкторлары беркетелделәр. Алар колхозларга барып практик ярдәм оештыралар.

Механизатор кадрлар әзерләү буенча да беркадәр уңышларыбыз бар. МТС каршында оештырылган курсларда байтак иптәшләр укып чыктылар. Алар игеннәрне урып-җыю вакытында уңышлы эшләделәр. Хәзер комбайнчылар, трактор отрядлары бригадирлары әзерләү мәктәпләрендә 60 тан артык кеше укый.

Колхоз производствосының җаваплы постларына күтәрелгән иптәшләрнең күпчелеге үзләренә йөкләтелгән бурычны уңышлы үтиләр. Шундыйлар рәтенә Ленин исемендәге колхоз председателе Минһаҗов, Каганович исемендәге колхоз председателе Нигъмәтҗанов, «Ирек» колхозы председателе Нигъмәтуллин һәм «Кызыл кабакса» колхозы председателе Сибгатуллин, авыл советы председателе Фәезова һәм башка иптәшләрне кертергә мөмкин. Алар җитәкчелек итә торган колхозлар быел игеннәрне урып-җыю, ашлык сугу һәм дәүләткә ашлык тапшыру эшләрен тулысы белән төгәлләделәр. Хәзер бу колхозларда язгы чәчүгә әзерлек эшләре киң җәелдерелде. Авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлау, орлык чистарту, кышкы агрочараларны үткәрү планы үтәлеп бара.

Терлекчелек өлкәсендә дә үзенең бурычларын тулысы белән аңлап, үрнәкле эшләүче кадрлар шактый. Менә Ленин исемендәге колхоз фермасы мөдире Шамакова, «Марс» колхозы фермасы мөдире Хатизов, Симетбаш колхозы фермасы мөдире Җәләлиева иптәшләрне алыйк. Алар терлекләрне кышлатуга әзерлек буенча яхшы эшләделәр. Терлек абзарлары вакытында ремонтланды. Җитәрлек кадәр терлек азыклары әзерләнде. Шулай ук бу колхозларда фермада эшләү өчен кадрлар әзерләүгә дә җитди әһәмият бирелә.

Ләкин шуны әйтергә кирәк, безнең районда әле җитәкчелек постларына яңа күтәрелгән иптәшләрнең эш тәҗрибәләрен уртаклашу тиешле югарылыкта түгел. Киләчәктә моңа әһәмият бирергә, эшкә яңа күтәрелгән кадрларны тәрбияләү, аларга практик ярдәм күрсәтү буенча һәрбер партоешма җитди шөгыльләнергә тиеш.

Г. ШӘРӘФИЕВ,
ВКП(б) ның Әтнә райкомының кадрлар буенча секретаре.

Экономия өчен көрәштә партоешма

Мехкомбинат янындагы партоешма соңгы айларда экономия мәсьәләләре белән җитәкчелекне шактый ук яхшыртты. Бу мәсьәлә партбюро утырышларында, партия җыелышларында тикшерелә. 22 нче октябрьгә «Комбинатта экономия өчен көрәшнең торышы» турында партия-хуҗалык активы җыелышында да каралды. Бу җыелышларда кабул ителгән карарларның үтәлешенә ныклы контроль булдырылды. Шушыларның нәтиҗәсе буларак, комбинатта соңгы айларда электр энергиясе һәм ягулык буенча экономия шактый үсте.

Мәсәлән, комбинат буенча бу елның 10 ае эчендә электр энергиясенә 263 киловатт сәгать экономия ясалган. Ә инде ноябрь аенда экономия тагын да артты. Шулай ук ягулыкны, чималны экономияле тоту буенча да уңышлар бар. Бу әле беренче уңышлар гына. Комбинатта электр энергиясен, ягулыкны һәм чималны тагын да экономияле тоту өчен мөмкинлекләр зур.

Ягулыкка экономия өчен көрәштә җитәрлек түгел әле. Казаннарда парны үлчи торган приборлар куелмаган. Ягулык бернинди үлчәүсез җибәрелә.

Продукциянең үзенә төшкән бәясен киметү планы да үтәлми.

Комбинатта булган цифрлар аерым фабрикаларда әле экономия өчен көрәшнең начар булуын ачык күрсәтәләр. Әгәр дә фабрикаларның җитәкчеләре хуҗаларча эш итсәләр иде, үзенә төшү бәясен киметү планын үтәү генә түгел, арттырып үтәгән дә булыр иде. Моны Скорняк фабрикасының (директоры иптәш Ионов) эшендә булган уңышлардан ачык күреп була. Бу фабрика үзенә төшкән бәясен киметү планын 4 миллион 162 мең сумга арттырып үтәгән.

Партоешма, экономия өчен көрәшне тәэмин итүгә барлык коллективны тупларга тиеш. «Һәр нәрсәгә экономия!»—бу, сугыш вакыты законы. Моны һәрбер җитәкче, һәрбер эшче исендә нык тотарга тиеш.

С. АХМЕТОВА.

ЯХШЫ ҖИТӘКЧЕЛЕК НӘТИҖӘСЕ

Саба районында башлангыч партоешмаларның күбесе политик эшне хуҗалык эшләре белән нык бәйләп баралар. Социалистик ярышка яхшы җитәкчелек итәләр. Агитаторлар ярышның нәтиҗәләренә йомгак ясыйлар. Алдынгыларның эш тәҗрибәләрен киң популярлаштыралар.

Мәсәлән, Эзмә авылы янындагы кандидатлар группасы. Ул авыл хуҗалыгының һәрбер тармагында социалистик ярышны киң җәелдерүгә турыдан-туры җитәкчелек итә. Бирәдә политик тәрбия эшләре дә яхшы куелган. Уку йорты, клуб һәм иреклә оешмаларның эшләре план буенча алып барыла. Политик беседалар колхоз эшенә бәйләп системалы рәвештә үткәрелә. Эшнең уңышлы нәтиҗәләре күз алдында. Бу оешмага караган «Игенче» колхозы игеннәрне урып-җыюны районда беренче булып төгәлләде. Ашлык сугу, дәүләткә ашлык тапшыру эшләре дә вакытында төгәлләнде.

Оет, Олы Шыңар авыллары янындагы башлангыч партоешмалар да авыл хуҗалыгы эшләренә якыннан торып җитәкчелек итәләр. Бу авылларда эш барлык тармакларда да яхшы бара. Коммунист иптәш Мөбарәков җитәкчелек итә торган «Авангард» колхозы дәүләт алдындагы йөкләмәләрен яхшы итеп үтәп чыкты.

С. ШАКИРОВ.

ЮЛБАШЧЫБЫЗНЫҢ КОТЛАВЫНА ЭШЛЕКЛЕ ҖАВАП БИРИК!

Язгы чәчүгә әзерлек яхшы бара

БИЛӘР. (Телефон буенча). «Эшән» колхозы членнары язгы чәчүгә яхшы әзерләнәләр. 56 тырма, 24 сабан, 13 культиватор һәм 2 чәчү машинасы ремонттан чыкты инде. Сука камытлары әзер. Ремонтта эшләүче иптәш Нуретдинов көнлек норманы 200 процентка үти. Орлык тазарту, кар тоту һәм башка эшләр дә яхшы бара.

* * *

ЧИСТАЙ. (Телефон буенча). «Индустрия» колхозында язгы чәчүгә әзерлек көннән-көн җәелә. 56 тырма, 8 культиватор, 3 чәчү машинасына ремонт үткәрелгән. Тимерче иптәш Коновалов норманы һәркөн 150 процентка үти. Чәчү орлыклары әзер. Орлык тазартуда эшләүчеләрдән Гарифуллина, Яруллина, Габйуллина һәм башка күп кенә иптәшләр көнлек норманы 120—130 процент итеп үтиләр. Кар тоту һәм басуга тирес чыгару уңышлы бара.

АШЛЫК ҺӘМ ЯШЕЛЧӘ

ЧАЛЛЫ, 4 январь. (Телефон буенча). Бикләп авыл советына караган Чкалов исемендәге колхоз членнарының гомуми җыелышы булды. Җыелышта иптәш Сталинның Татарстан колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына җибәргән телеграммасы укылды. Колхозчылар җитәкченең рәхмәтенә җавап итеп Кызыл Армия фондына 300 пот ашлык бүләк иттеләр. Колхоз председателе Садыйков һәм ферма мөдире Шакиров иптәшләр 12 шәр пот бирделәр.

Ә. ӘХСӘНОВ.

* * *

«Память Ленина» колхозы (Столбище районы) кырларында күбрәк урын яшелчәгә бирелә. Яшелчә үстерү колхозның төп эше булып санала. Бу эшне колхозчылар бик яратып башкаралар.

Яшелчәләрне яхшы итеп тәрбияләп үстерү сәбәпле узган җәйдә мул уңыш алдык. Колхоз дәүләткә бәрәңге тапшыру планын 165 процентка җиткереп үтәде. Төрле яшелчәләр буенча да задание күп тапкырлар арттырып үтәлде. Колхоз яшелчә тапшыру планын 1.211 процент итеп башкарды. Болар өстенә тагын кооперация аркылы дәүләткә 3.800 центнер бәрәңге һәм яшелчә сатылды.

Героик Кызыл Армиябезнең җиңүле һөҗүмнәре колхозчыларны фронтка ярдәм итүгә нык туплады. Кызыл Армия фондына тагын 50 центнер бәрәңге һәм яшелчә тапшырылды. «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасын төзүгә колхозчылар 120 мең сум средство туплап бирделәр.

Бөек юлбашчының Татарстан колхозчыларына җибәргән сәламен һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен ишеткәч, без эшчәнлекне күп тапкырлар арттырдык. Яшелчә орлыклары колхозның чәчү мәйданына җитәрлек итеп әзерләнде. Хәзер ашламалар җыю һәм аларны басуга чыгару эше белән шөгыльләнәбез. Язгы чәчү вакытында кирәкле булачак авыл хуҗалыгы коралларына ремонт кызу темп белән бара.

ГРАНКИН,
колхоз председателе.

Столбище районы, Клим Ворошилов исемендәге колхоз членнары Татарстан колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына иптәш Сталинның котлау телеграммасын гаять зур рух күтәренкелеге белән каршыладылар. Шушы уңай белән колхозда гомуми җыелыш булды. Колхозчылар самолетлар һәм танклар төзүгә яңадан средство җыярга карар бирделәр. Рәсемдә: авыл советы председателе иптәш Осипов гомуми җыелышта иптәш Сталинның котлау телеграммасын укый.

К. Тахтеев фотосы.

САМОЛЕТ ТӨЗҮГӘ

АПАС, 4 январь. (Телефон буенча). Иптәш Сталин телеграммасы колхозларда яңа зур җанлану тудырды. Бу уңай белән үткәрелә торган митингларда чыгып сөйләүче колхозчылар героик Кызыл Армиябез өчен бернәрсәләрен дә кызганмауларын, явыз дошманны тизрәк җиңү өчен тагын да тырышыбрак эшләргә әзер торганлыкларын белдерәләр.

«Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә район буенча 1 миллион 400 мең сум акча җыелган иде инде. Иптәш Сталинның рәхмәт телеграммасы алыну белән бу патриотик хәрәкәт тагын да көчәйде.

«Тырышчы» колхозы колхозчылары кичә гомуми җыелыш үткәрделәр. Колхозчылар самолетлар төзелешенә колхозның гомуми фондыннан 135.000 сум акча кертергә карар бирделәр. Шулай ук колхозчылар бу төзелешкә үз акчаларын да бирәләр. Мәсәлән, колхоз председателе иптәш Галиев 45.000 сум, ферма мөдире, кызылармеец хатыны Рәшидә иптәш Билалова 22.500 сум бирделәр.

Үз хуҗалыкларындагы ашлык запасларыннан Кызыл Армия фондына ашлык бүләк итүчеләр саны да «Тырышчы» колхозында көннән-көн күбәя. Алар бу фондка 100 пот ашлык бирделәр инде. Колхозчы Хөсниев, Будаев һәм Нәҗмиев иптәшләр 12 шәр пот бирделәр.

СВОДКА

ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

1943 нче елның 1 нче январена

(ПЛАНГА КАРАТА ПРОЦЕНТЛАРДА)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
1. Мөслим	83,0	37. Юдино	40,0	74. Солтан	20,6
2. Норкәй	80,0	38. Зирекле	38,4	75. Рождественский	20,3
3. Тымытык	75,7	39. Буа	37,1	76. Тельман	19,7
4. Ишеево	74,2	40. Баулы	37,0	77. Алексеевский	19,6
5. Чүпрәле	69,8	41. Чүрибураш	36,1	78. Калинин	18,0
6. Чокалы	69,1	42. Т. Тамак	35,9	79. Арча	18,0
7. Саба	66,0	43. Кукмара	35,8	80. Кызыл юл	17,7
8. Бөгелмә	59,5	44. Бондюг	35,6	81. Морт	17,6
9. Тархан	59,0	45. Яңа Чишмә	35,8	82. Чиябаш	17,5
10. Тирсә	57,5	46. Сарман	32,0	83. Каргалы	16,7
11. Кызыл йолдыз	57,0	47. Иске Чишмә	31,8	84. Биектау	16,6
12. Поповка	53,7	48. Кузнечиха	31,7	85. Аксубай	16,0
13. Юртыш	53,6	49. Казанбаш	30,3	86. Балык бистәсе	16,0
14. Соколка	53,0	50. Алга	30,0	87. Иске Тимошкино	15,8
15. Алабуга	52,8	51. Куйбышев	29,8	88. Әхмәт	15,7
16. Дәүләкә	52,1	52. Питрәч	29,8	89. Константиновка	15,4
17. Кадряк	51,4	53. Кәкре елга	29,5	90. Минзәлә	15,2
18. Мөслим (Чистай)	50,5	54. Акташ	29,3	91. Столбище	14,8
19. Заинский	50,0	55. Шөгер	28,3	92. Чаллы	14,6
20. Октябрь	50,0	56. Б. Матак	27,5	93. Әлшн	14,3
21. Әлмәт	50,0	57. Иске Писмән	26,6	94. Майдан	13,8
22. Яниль	50 0	58. Кичү	26,0	95. Салман	13,1
23. Олы Карлие	50,0	59. Тәтеш	25 0	96. Т. Ходяш	8,8
24. Норлат	50,0	60. Буденный	24,6	97. Мамадыш	8,2
25. Зоя	50,0	61. Теләче	24,5	98. Тат. Ялтан	7,5
26. Кузайкино	49,1	62. Чаллы	24,3	99. Карамалы	7,3
27. Беренче Май	49,0	63. Маткавыш	24,1	100. Зур Поляна	7,0
28. Чистай	49,0	64. Черемуховский	24,0	101 Ключи	6,9
29 Чыбыклы	48,9	65. Кама тамагы	23,3	102. Кошкино	6,5
30. Ютазы	48,0	66. Димитров	22,8	103. Чишмә	6,1
31. Мәлки	48,0	67. Биләр	22,2	104. Үзәк	5,9
32. Кызыл чапчак	46,4	68. Ромадан	22,2	105. Әлки	5,8
33. Азин	45 2	69. Әтнә	22,0	106. Махыл	3,8
34. Дөбьяз	41,4	70. Исәнбай	21,6		
35. Актаныш	40,9	71. Балтач	21,1	Барлыгы:	32,2
36. Мөрәле	40,4	72. Трехозерский	20,7	1942 нче елның	
		73. Тәкәнеш	20,6	25 нче декабренә	24,0

Тагын да яхшырак эшләрбез

Без күп кенә авылдашларыбызны фронтка озаттык. Моңа карап колхозыбызда эш һич тә йомшармады. Урып-җыюны уңышлы тәгәлләп, дәүләткә ашлык тапшыруны 105 процент итеп үтәдек. Фермерлар буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәгәннән соң 1943 нче ел исәбенә 12 центнер ит тапшырдык.

«Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасында безнең колхозның да танклары булачак. Колхозчылар танклар төзү өчен үзләренең саклык акчаларыннан 86.000 сум средство тупладылар. Моның өчен без дә бөек юлбашчыбыз котлавына лаеклы булдык. Аның сәламенә һәм Кызыл Армиянең рәхмәтенә җавап итеп тагын да яхшырак эшләрбез. 1943 нче елда фронт өчен кирәк булганнарның барысын да бирербез.

ХИСМӘТУЛЛИН.
Биектау районы, Вахитов исемендәге колхоз председателе.

Авылдашларыбыз безнең акчага ясаган кораллар белән сугышсыннар

Тамбовлыларның танклар колоннасы төзүгә средство туплап, юлбашчыбызга биргән рапортлары турында радиодан ишеткәч без дә митингка җыелдык. Анда беренче сүзне карт колхозчы иптәш Кантаков алды. Аның 4 улы фронтта. Ул бераз дулкынланып сүзгә керешге.

— Минем илемнең азатлыгы өчен батырларча көрәшүче уллар үстерүем белән мактана алам. Сугыш техникасы нык булсын. Танклар төзү өчен колхозыбыздан тупланган акча ун меңнәрчә җыелсын. Мин үземнең саклап җыйган акчамнан 1.800 сум бирәм. Авылдашларыбыз үзебезнең средствога төзелгән кораллар белән сугышсыннар,— диде.

Нәтиҗәдә, колхозчылардан берничә көн эчендә 86.000 сум акча җыелды. Шуның өстенә без, дәүләт заданиеләрен үтәгәннән соң, тагын фронтовиклар өчен 2.000 килограмм ит, 1.006 литр сөт җибәрдек.

ПРЕСНАЯ,
Югары Ослан районы, Ворошилов исемендәге колхозның правление члены.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

5 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

5 нче январьда безнең гаскәрләр **Донның** урта агымы районында, **Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак** һәм **көньяктарак, Үзәк фронтта** һәм **Төньяк Кавказда** элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар. Безнең гаскәрләр **Нальчик** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, **Прохладный** шәһәрен һәм тимер юл узелын, **Майское** шәһәрен һәм **Котляревская** тимер юл узелын, **Морозовский** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, район үзәге **Цымлянсканы** алдылар.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең снайперлар һәм разведчиклар 100 дән артык гитлерчыны юк иттеләр. Сталинградтан көнбатыштарак безнең частьлар әһәмиятле ике биеклек өчен каты сугышлар алып бардылар. Артиллерия уты ярдәме белән безнең сугышчылар дошман урнашкан урынга барып кереп, дошманның 20 окобын һәм блиндажын алдылар. 4 орудие, 16 пулемет, 134 винтовка кулга төшерелде. Пленныйлар алынды.

Сталинград районында бер көн эчендә немецларның 9 самолеты бәреп төшерелде.

* * *

Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Уңайлы бер чик якынында бик каты сугыш булды. Гитлерчылар, үзләренең позицияләрен ничек кенә итеп булса да тотып калырга омтылып, шактый күп көчләр җибәрделәр. Совет артиллеристлары, ачык позицияләрдән атып, дошманның ут каршылыгын бастырдылар һәм безнең пехотабызга юл ачтылар. Сугышчылар, кискен төстә ыргылып, немецлар урнашкан урынга бәреп керделәр һәм аларны чигенергә мәҗбүр иттеләр. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 11 орудие, 7 миномет; 28 пулемет һәм бер сугыш припаслары склады бар. Сталинградтан көньяктарак, безнең подразделениеләр, чигенүче дошманны куып барып, немецларның бер батальон пехотасын тар-мар иттеләр.

* * *

Донның урта агымы районында безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта Н-че часть сугышчылары дошманның чолганып алынган һәм каршылык күрсәткән гарнизонын кырып бетерделәр. Немецларның авиапехота дивизиясе частьларыннан пленныйлар алынды. Шулар арасында полк командиры плен алынды. Икенче бер участокта безнең укчы частьлар, штурм ясап, Морозовский шәһәрен һәм зур тимер юл станциясен алдылар. Пленныйлар алынды һәм бик күп трофейлар кулга төшерелде. Трофейларның исәбе алына.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр үзләре алган чикләрне ныгыттылар һәм аерым участокларда һөҗүм сугышлары алып бардылар. Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак дошман пехотасы, танклар ярдәме белән, безнең частьларга атака ясарга маташты. Гитлерчыларның барлык атакалары алар өчен зур югалтулар белән кире кайтарылды. Күрше участокта командиры иптәш Стариков булган подразделение немецларның 19 автомашинасын, бер орудиесен, бер сугыш припаслары складын һәм 25 атын кулга төшерде. Безнең сугышчылар мылтык һәм пулемет уты белән немецларның 2 самолетын атып төшерделәр.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр һөҗүмне уңышлы рәвештә җәелдерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Нальчикка килү юлларында каты сугышлар булды. Немецлар шәһәрне күп кенә куәтле инженерлык корылмалары белән чолгап алганнар һәм барлык юлларга миналар куйганнар иде. Безнең сугышчылар, артиллерия һәм танклар ярдәме белән, барлык тоткарлыкларны җиңеп, төнлә белән шәһәргә бәреп керделәр һәм кискен атакадан соң аны алдылар. Нальчикка килү юлларында һәм шәһәр урамнарында дошман солдатларының һәм офицерларының йөзләрчә үле гәүдәләре калды. Икенче бер участокта безнең гаскәрләр көнчыгыштан һәм көньяктан Прохладный шәһәренә бәреп керделәр һәм бик каты сугыш нәтиҗәсендә шәһәрне немецлардан чистарттылар. Тулы булмаган саннарга караганда, 25 танк һәм бронемашина, 27 орудие; 37 пулемет, 1.000 винтовка, 63 автомашина һәм 6 склад кулга төшерелгән. Трофейларның санын алу дәвам итә.

* * *

Минск өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды сугыш хәрәкәтләренең 10 көне эчендә немецларның 2 гарнизонын юк иткән һәм дошманның 4 тимер юл эшелонын юлдан чыгарган. 4 паровоз һәм 28 вагон җимерелгән. Оккупантларга каршы сугышларда һәм поездлар һәлакәте вакытында 400 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары кырылган. Бер радиостанция, 7 пулемет, 120 винтовка һәм берничә мең патрон кулга төшерелгән.

* * *

Түбәндә Орджоникидзе краеның Ленин поселогында немец фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Гитлерчы бандитлар безнең колхозны һәм поселокта торучыларны таладылар. Немецлар колхозчы Новикозның сыерын, бозавын, 5 сарыгын талап алдылар, колхозчы Раkованың 4 сарыгын һәм яшь үгезен суйдылар. Бу талаучылар барлыгы 3.000 сарыкны, 300 баш эре терлекне һәм күп кенә йорт кошларын суйдылар яки үзләре белән алып киттеләр. Немецлар күп колхозчыларның кыйммәтле әйберләрен талап алдылар һәм йорт җиһазларын ватып бетерделәр. Гитлерчылар колхоз фермасын, колхозның ат абзарын һәм башка җәмәгать каралтыларын юк иттеләр. Фашистлар халык белән ерткыч төстә мөгамәлә иттеләр, колхозчыларны кыйнадылар, гражданнар халкын төрлечә мыскылладылар». Актка колхозчылардан А. Новикова, Н. Черных, А. Ракова һәм М. Новаковалар кул куйган.



АКШ тагы авиация заводларыннан берсендә транспорт самолетларын җыю цехы.

ТӨНЬЯК АФРИКАДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 4 январь. (ТАСС). Рәсми хәбәрләргә караганда, кичә Триполитаниядә зур сугыш операцияләре булмаган.

ЛОНДОН, 4 январь. (ТАСС). Франция командованиесенең белдерүендә әйтелүенчә, кичә иртә белән дошман Пон-дю-фастан көньяк-көнчыгыштарак Франция гаскәрләренә атака ясаган. Бик каты сугыштан соң дошман Кайруанга чигенергә мәҗбүр булган. (Пон-дю-фас Тунистан 30 миль көньяк-көнбатышта булган бер пункт, Кайруан—Тунистан 80 миль көньяктарак урнашкан).

Франциянең моторлаштырылган гаскәрләре генерал Леклерк командалыгында Чад белән Ливия территориясе арасындагы чиктән башлап берничә йөз миль араны үткәннәр һәм төньякка таба баруда дәвам итәләр.

2 нче январьда Англия танклары Меджез-Эль Бабтан көнчыгыштагы районда рейд ясаганнар.

ЛОНДОН, 4 январь. (ТАСС). Рәсми хәбәрләргә караганда, 2 нче январьда союзниклар авиациясе дошманның коммуникацияләренә каршы операцияләр алып барган һәм Ла-Гулетт пристанена зур һөҗүм ясаган. Стратегия ягыннан әһәмиятле булган районнарда бик күп янгыннар чыккан һәм шартлаулар булган.

Дошман Бонга һәм Алжирга берничә тапкыр һөҗүм ясарга маташкан, ләкин союзниклар тарафыннан куылган.

2 нче январьдагы һава сугышлары нәтиҗәсендә дошманның 28 самолеты атып төшерелгән һәм 34 самолеты сафтан чыгарылган.

ФРОНТТАН ХАТ

ДОШМАН ТРАНШЕЯСЫНДА

Алда—чәнечкеле тимер чыбыкларның кара стенасы күренә. Разведчиклар, саперлар белән берлектә, тавышсыз гына тимер чыбыкларның куе рәтләренә килеп җитәләр. Кызылармеецлардан Синева һәм Каменский бик тиз генә кайчылар белән чәнечкеле тимер чыбыкларны кисәләр һәм үтү өчен юл ачалар.

Чәнечкеле тимер чыбыклар аша «капкалар» эшләнә. Саперлар мина эзләгеч белән юлларны тикшерәләр. Миналар табылмый. Сигнал бирелә. Разведчиклар, группаларга бүленеп, алдан билгеләнгән урыннарга юнәләләр. Автоматчиклар группасы дошман траншеяларына якынлаша.

Бер минутка тынлык. Разведчиклар тын да алмыйча көтәләр. Алар дошман окобы буйлап бер немец солдатының һәм аның артыннан икенчесенең үтеп киткәнен ишетәләр. Аларның соңгысы окоптан башын чыгарып карый да, кар белән бер төсле булып яткан безнең разведчикларның фигураларын күреп ала.

— Хальт!—дип акыра немец.

— Алга!—дигән команда бирелә һәм сержант Евдокимов беренче булып граната ыргыта. Гранаталар шартлаудан гитлерчылар аптырашта калалар. Окоплар белән рәттән урнашкан ДЗОТ тан алар йөгерешеп чыгалар һәм шунда ук безнең автоматчикларның пуляларыннан кырылабаралар. Евдокимов дошман траншеясына сикереп төшә, качып баручы немецларга автоматтан бер очередь җибәрә дә, иптәшләренә кисәтү ясап, үзе немецлар артыннан буранлай булып йөгерә башлый.

Шул ук вакытта разведчикларның икенче группасы немецларның сулъяк флангысын кисеп ала һәм беренче группадан игътибарны читкә юнәлтү өчен бик каты атыша башлый.

Автоматчиклар да хәрәкәтсез тормыйлар. Сугышчы Саакеев, башка сугышчылар белән бергә, траншеяга сикереп төшә һәм сержант Евдокимовка ярдәм итә.

Яраланган бер немецны бәйләп алалар. Башка окоплардагы немецлар хәлне төшенеп алалар да, пулеметлардан, автоматлардан, винтовкалардан, хәтта авыр минометлардан да котырынып ут ачалар, ләкин инде соң була. Безнең разведчиклар атыша-атыша үзләренең оборона линиясенә кайталар.

Операция уңышлы үтә. Бу уңышка ирешүдә—тиз хәрәкәт итү, батырлык һәм разведчикларның дисциплиналылыгы хәл иткеч роль уйный. Ике дистәгә якын гитлерчы кырыла, немецларның бик көчле бер ДЗОТ ы җимертелә һәм бер «тел» штабка китереп тапшырыла.

Өлкән лейтенант **С. ТАБАКМАН.**

Гитлерчылар тарафыннан оккупацияләнгән илләрдә Германиягә каршы саботаж

НЬЮ-ЙОРК, 4 январь. (ТАСС). Алынган хәбәрләргә караганда, Шартрезда (Франция) ике авыл хуҗалыгы предприятиесендә янгын чыгып, немецларның алардагы барлык азык запаслары юкка чыккан.

СТОКҺОЛЬМ, 4 январь. (ТАСС). Матбугатта хәбәр ителүенә караганда, Нерланд янында зур шартлау булып, немецларның радиопеленгация станциясе юк ителгән. Бу станцияне бер немец солдаты шартлаткан. Ул, станцияне шартлаткан вакытта үз-үзен үтергән.

Берген янындагы бер зур аэродромда немец техникларь бюросы урнашкан бина янган. Күп кенә кыйммәтле материаллар янып беткән.

НЬЮ-ЙОРК, 4 январь. (ТАСС). Бельгиянең бер гражданины Гент шәһәрендә күп кенә саботаж актлары ясаган. Гитлерчылар бу кешене тотып бирүчегә 100 мең франк бүләк бирәчәкләрен игълан иткәннәр.

ЖЕНЕВА, 4 январь. (ТАСС). Яңа елга каршы төндә Брюссельдә (Бельгия) Германиянең өч солдаты үтерелгән. Шул уңай белән Германиянең бу шәһәрдәге хәрби коменданты барлык җәмәгать юлларын, махсус боерык булганга кадәр, ябарга приказ биргән. Кичке 8 сәгатьтән соң урамнарга чыгу тыелган. Немец комендантының приказында әйтелүенчә, «шикле кешеләр» кулга алынганнар.

ГЕРМАНИЯ КОРАБЛЕН БАТЫРУ

ЛОНДОН, 4 январь. (ТАСС). Диңгез министрлыгының хәбәр итүенә караганда, Англиянең сакчы корабльләре Атлантик океанда дошманның 10.000 тонна авырлыгындагы бер сәүдә пароходын очратканнар. Бу пароход блокада аркылы үтеп чыкмакчы булган. Немецлар командасы пароходны батырган һәм плен алынган.

Америка самолетларының Сен-Назерга һөҗүме

ЛОНДОН, 4 январь. (ТАСС). Англия информация министрлыгының хәбәр итүенә караганда, 3 нче январь көндез Американың авыр бомбардировщиклары Сен-Назердагы докларга һөҗүм иткәннәр. Бомбардировщикларны 300 гә якын истребитель саклап барганнар. Дошман авиациясе доклар янында гына каршылык күрсәткән. Анда дошманның күп сандагы истребительләре бомбардировщикларга атака ясаганнар. Һава сугышы нәтиҗәсендә дошманның берничә самолеты юк ителгән. 7 бомбардировщик үзләренең базаларына кайтмаганнар. Истребительләрнең югалтулары булмаган.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Зур драма театры. Бүген көндезге 12 сәгатьтә — „Рус кешеләре“, кич 7 сәгать 30 минутта — „Күренми торган ханым“.

Татар дәүләт филармониясе. Менжинский исемендәге клубта бүген һәм 6 нчы, 7 нче һәм 8 нче январьда Кишинев дәүләт джазы „Молдавия“ның концертлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

Дәүләт циркы. Бүген зур цирк тамашасы Кичке 11 сәгатьтә орденлы композитор Дмитрий Покрасс житәкчелегендә Москва тимер юл джаз-оркестрының гастроле. Кич 11 сәгатьтә башлана.

„Электро“ художестволы яңа фильм —„Райком секретаре“.

„Пионер“ — „Антон Иванович ачулана.“

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 807 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 29